**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

12.10.2024 № 346

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны алдан карап тикшерү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында» 2005 елның 8 ноябрендәге 320 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 19 ноябрендәге 305 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге 97 номерлы, 2011 елның 13 апрелендәге 171 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге 550 номерлы, 2014 елның 5 маендагы 310 номерлы, 2015 елның 2 ноябрендәге 640 номерлы, 2017 елның 18 сентябрендәге 557 номерлы, 2019 елның 16 ноябрендәге 376 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 353 номерлы боерыклары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 136 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны алдан карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан И.Ф. Бәдриевны, М.В. Ляукинны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Кириллов Евгений Викторовичны – Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе хокукый экспертиза бүлеге мөдирен;

Сабурская Алина Викторовнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгын.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ